КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 31 октябрь г.Казань № 890

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 25 декабрь, 892 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләрне, дини һәм милли туфракта конфликтларны иртә кисәтүмониторинглауның комплекслы системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм дини һәм милли нигездә низагларны кисәтү системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентын раслау турында» 2015 ел, 25 ноябрь, 892 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 9 июнь, 385 нче, 2016 ел, 21 ноябрь, 859 нчы, 2023 ел, 22 май, 625 нче, 2023 ел, 22 июнь, 736 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында милләтара һәм конфессияара мөнәсәбәтләр торышын мониторинглау һәм дини һәм милли нигездә низагларны кисәтү системасында катнашучыларның мәгълүмати хезмәттәшлеге регламентына, 2.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәп, үзгәреш кертергә:

«Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе» дәүләт фәнни бюджет учреждениесе һәм Татарстан Республикасы Рәисенең Эчке сәясәт мәсьәләләре буенча департаменты белән үзара хезмәттәшлектә комплекслы мониторинг системасының функциональ операторы булып тора. Дәүләт заказчысы һәм комплекслы мониторинг системасының техник операторы булып «Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе тора.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин